# Сәгыйть Рәмиев

Татар әдәбиятыннан проектны эшләде 6 сыйныф укучысы Марданшина Миләушә. Җитәкче татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гыймаева Зөлфия Фәһим кызы

# Сәгыйть Рәмиевның балачагы



- Сәгыйть Рәмиев 1880 елның 24 февралендә Оренбург төбәгендә Акман авылында туа. Аның гаиләсе бер урында гына тормый, вакыт-вакыт күчеп йөрергә мәҗбүр була. Сәгыйть 1890 елдан 1902 елга кадәр "Хөсәения" мәдрәсәсендә белем ала. Ул бу вакытта гарәп, фарсы, төрек телләрен, әдәбият үрнәкләрен нигезле өйрәнгән. Ул "Хөсәения"дә мөгаллим булып кала.
-

# Журналистик эшчәнлеге


- Сәгыйть Рәмиев 1906 ел башында Казанга килә. Анда "Таң йолдызы" газетысындә әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Ә 19 июньнән аның мөхәррире итеп билгеләнә. Тиздән газета ябыла, С.Рәмиев төрмәдә бер ай утырып чыга. Ул "Тавыш" исемле газета да оештырып карый.
- "Таң йолдызы" дәвамчысы буларак "Таң мәҗмугасы" исемле журнал чыгару эшенә керешә. Реакция чорында күп газет-журналлар ябыла. Сәгыйть Рәмиев, бөтенләй эшсез калгач, "Бәянел-хак" газетасы редакциясендә эшли башлый. 1910 елда Әстерханга китеп, андагы "Идел" газетысында сәркатип булып эшли башлый. Дөресендә әлеге басманың мөхәррире хезмәтен үти.

# Сәгыйть Рәмиев



- Сәгыйть Рәмиев 1914 елда өйләнә. Гаиләле булып өч ай үткәч, "Идел" газетасын ябалар һәм Сәгыйть Рәмиевне Әстерханнан сөрәләр. Ул аннан хатынының туган җире Уфага китә. Монда рус телендә чыгучы "Авыл көнкүреше журналы"на эшкә урнаша – аны татарча тәрҗемәсен чыгара. Гражданнар сугышы башлангач, Уфадан Урал өязенең Ваһапов поселогына китәргә мәҗбүр була. Анда ревком сәркатибе итеп билгеләнә. Магнитка станциясендә мәгариф эшләренә җитәкчелек итә. Верхний Урал шәһәрендә партия комитетының мөселманнар секциясендә хезмәт итә,Чиләбедә чыгучы "Кызыл Урал" газетысында да эшләп ала (1921-1922, андагы педагогия техникумында татар әдәбиятын укыта. Уфага кайткач (1922 ел ахыры), Җир эшләре халык комиссариатында нәшрият эшләре җитәкчесе була. Ләкин сәламәтлеге начарая башлый һәм ул 1926 елның 17 нче мартында үпкә авыруыннан үлә.
- .

# Өч дус, өч шагыйрь.



- Тукай аягын эскәмиягә куйган, уртада Сәгыйть Рәмиев, җирдә – Фәхрелислам Агиев.

# Әстерханда



- Әстерханда 1911 елның җәендә төшерелгән фоторәсем. Урта рәттә сулдан: артист Зәйни Солтанов, Габдулла Тукай, шагыйрь Сәгыйть Рәмиев.
- 

# Сәгыйт Рәмиев



- Сәгыйт Рәмиев белән артист Зәйни Солтанов.

# Шигырьләр

- Уян, татар!
- Гасыр башы!
- Күпме бөек шагыйрь
- Иҗат иткән ошбу дәвердә.
- Дәрдмәнд, Тукай, Рәмиевлар -
- Булырлар гел безнең хәтердә.
- Онытмыйбыз без аларны,
- Үтсә дә бик күп еллар.
- Татарымның шәхесләрен
- Без зурламый, кем зурлар.
- Бүген килдек, Сәгыйть, янына,
- Беләбез чөнки синең кадерне.
- Һәр ел саен, чиксез хөрмәтләп,
- Күреп китәбез синең каберне.
  Синең янда басып торганда
- Башым әллә ниләр уйлана.
- Халкым, телем киләчәге өчен
- Күңелем дә минем сызлана.

- "Сызла,сызла, сызла, күңелем"
- Сызла син халкың өчен.
- Яшәгәннәр бит шагыйрьләр
- Жәлләми һич бер көчен.
- "Уян, татар!", - дип оран салдың,
- Арындык без шул чак уйкудан.
- Яшәү дәрте бездә уянды
- Синең иҗатыңны укудан.
- Иҗатыңа, шагыйрь, сокланып,
- Үтеп китә минем көннәрем.
- Синең сүзләреңә ияреп,
- Килә минем шуны әйтәсем:
- Иҗатка юнәлтүчем ул - син!
- Туры юлга күндерүчем ул - син!
- Акыл биргән, нурлар чәчкән,
- Изге рухлы кешем дә - син!



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

MyShared